КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 9 июнь г.Казань № 782

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 9 июль, 554 нче карары белән расланган Социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге объектларны урнаштыру, масштаблы инвестицион проектларны тормышка ашыру өчен дәүләт милкендәге яки муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен юридик затларга, сатулар үткәрмичә, арендага бирү тәртибенә үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге объектларны урнаштыру, масштаблы инвестицион проектларны тормышка ашыру өчен дәүләт милкендәге яки муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен юридик затларга, сатулар үткәрмичә, арендага бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 9 июль, 554 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 13 сентябрь, 864 нче, 2022 ел, 12 гыйнвар, 8 нче, 2022 ел, 30 июль, 738 нче, 2023 ел, 2 февраль, 85 нче, 2023 ел, 4 март, 206 нчы, 2023 ел, 31 июль, 909 нчы, 2023 ел, 31 август, 1047 нче, 2025 ел, 20 октябрь, 846 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге объектларны урнаштыру, масштаблы инвестицион проектларны тормышка ашыру өчен дәүләт милкендәге яки муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен юридик затларга, сатулар үткәрмичә, арендага бирү тәртибенә, 5.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«5.1. Җир кишәрлеген (җир кишәрлекләрен) арендалау килешүе юридик зат Татарстан Республикасы Рәисенең җир кишәрлеген (җир кишәрлекләрен) сатулар үткәрмичә арендага бирү турындагы боерыгы чыгу турында хәбәрнамә алган көннән соң 30 эш көненнән артмаган вакыт эчендә төзелә.

Бу пунктның беренче абзацында күрсәтелгән Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләренә карата хәбәрнамә Татарстан Республикасы Рәисенең җир кишәрлеген (җир кишәрлекләрен) сатулар үткәрмичә арендага бирү турындагы боерыгы чыккан көннән соң өч эш көне эчендә Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы тарафыннан юридик затка җибәрелә.

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләрен бирүгә вәкаләтле җирле үзидарә органнарына мондый җир кишәрлекләрен Тәртип нигезендә сатулар үткәрмичә юридик затларга арендага биргәндә билгеләнгән компетенция кысаларында юридик затларга Татарстан Республикасы Рәисенең җир кишәрлеген (җир кишәрлекләрен) сатулар үткәрмичә арендага бирү турындагы боерыгы күчермәсен алган көннән алып өч эш көненнән артмаган срокта хәбәр җибәрергә тәкъдим итәргә».

2. Бу карарның гамәле 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин